«Шатлык» балалар бакчасы» МББМБУ
татар теле тәрбиячесе Хөснетдинова Г. Х.

# Татар халкының милли ризыкларына шигъри сәяхәт

# Ашларыгыз тәмле булсын!

**Бавырсак һәм кош теле.**

**Ризыклар төрле-төрле:**

**Сумса, бәлеш, өчпочмак,**

**Гөбәдия һәм коймак.**



# Милләт горурлыгы – чәк-чәк



Милләтемнең горурлыгы,

Милли аш – тәмле чәк-чәк.

Күпләп капма, аз-азлап кап,

Юкса, бик тиз бетәчәк.

# Челтәр-челтәр кош телләре

**Чәй өстәлен аннан башка**

**Әзерләми Дәү әни.**

**Челтәр-челтәр кош телләре,**

**Капсаң авызда эри.**



# Табын күрке - гөбәдия



**Дөге, тура, йөземнәр**

**Матур итеп тезелгән.**

**Гөбәдия табын күрке**

**Булган элек-электән.**

# Алсу йөзле өчпочмаклар

Алсу йөзле өчпочмаклар

Иң яраткан ризыгым.

Үзе йомшак, үзе кайнар,

Бик тәмле булган, кызым!



# Бигрәк тәмле пәрәмәч



Пәрәмәч сүзен ишеткәч,

Авыздан сулар китә.

Китмәс иде, бик тәмле шул

Шуңа да ул тиз бетә.

# Милли сый – токмач ашы

**Гәрәбәдәй шулпасы,**

**Нечкә генә токмачы.**

**Киленнәрнең уңганлыгы –**

**Татарның токмач ашы.**



# Гади генә кыстыбый



**Өстәлдә кыстыбый булса,**

**Табын түгәрәк, диләр.**

**Аны бар да бик ярата,**

**Әти-әни, бәбиләр.**

# Татлы балан бәлеше

**Татар халкында бәлешнең,**

**Була бик күп төрлесе.**

**Сезгә тәкдим итим әле,**

**Татлы балан бәлешен.**



# Җиләк җыйдым – как койдым



Алма, карлыган, миләштән

Тел йотарлык как койдым.

Телем, телем, телемләп

Чәй табынына куйдым.

# Кызыл тәпи ак казлар

Туйларның бөтен яме,

Тозлы каз тәкъдим итү.

Борынгыдан килгән йола,

Безнең эш –дәвам итү.



# Бигрәкләр тәмле дучмак



**Әчегә дә, төчегә дә**

**Бик тәмле була дучмак.**

**Әни, дучмак пешерәм, дисә,**

**Шатланып куям шул чак.**

# Бәлешнең була төрлесе

**Кайнар мич куенында**

**Шулпалы бәлеш пешә.**

**Әнинең күңел җылысы**

**Шул бәлешләргә күчә.**



# Табын хуҗасы - коймак



**Майлы коймак табада**

**Бик тәмле булып пешә.**

**Коймак исе һәммәбезне**

**Чәй табынына дәшә.**